**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Исполнительный комитет**
**Асеевского сельского поселения**
**Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Азнакай муниципаль районы**
**Әсәй авылы**
**җирлеге башкарма комитеты**

ул. Центральная, д. 38 Б, село Асеево,
Азнакаевского муниципального района,
423310

Үзәк ур., 38Б нче йорт, Әсәй авылы,
Азнакай районы, 423310

Тел./факс(885592) 43-2-37; E-mail:Asv.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«04» февраль 2019 ел №1

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентлары турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 27.07.2010 елдагы 210-ФЗ номерлы Федераль законны тормышка ашыру максатларында карар бирәм:

1.Расларга:

1.1.Адресларны бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча административ регламент (1 нче кушымта );

1.2.Документлар күчермәләренә һәм алардан өземтәләргә тугрылык таныклавының Административ регламенты (2 нче кушымта);

1.3.Васыятьнамәләр һәм ышанычнамә таныклыклары административ регламенты (3 нче кушымта);

1.4.Белешмә (Өземтә) бирүнең административ регламенты (4 нче кушымта);

1.5.Агач һәм куаклар кисүгә рөхсәт бирү административ регламенты (5 нче кушымта);

1.6.Социаль наем шартнамәсе буенча бирелгән торак урыннарын алыштыру буенча документларны рәсмиләштерүнең Административ регламенты (6нчы кушымта);

1.7. Элек хосусыйлаштырылган торак биналарны муниципаль милеккә кабул итүнең административ регламенты (7 нче кушымта);

1.8.Муниципаль берәмлек чикләрендә тулысынча яки өлешчә җирле әһәмияттәге юллар буйлап уза торган маршрутлар буенча авыр йөкләрне, зур габаритлы йөкләрне автомобиль йөртүгә рөхсәт бирү административ регламенты (8 нче кушымта);

1.9.Муниципаль милектәге гражданга социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны бирү буенча административ регламент (9 нчы кушымта);

1.10. Торак биналарны гражданнар милкенә тапшырганда документларны рәсмиләштерүнең Административ регламенты (10 нчы кушымта);

1.11.Муниципаль торак фондында гражданнарга хезмәт торак урыны наймы шартнамәләре буенча торак урыннары бирүнең административ регламенты (11 нче кушымта);
1.12.Муниципаль милек реестрына керә торган муниципаль милекне арендага бирү буенча административ регламент (12 нче кушымта);
1.13.Аукцион уздырмыйча стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга килешү төзүнең Административ регламенты (13 нче кушымта);
1.14.Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларыннан файдаланучыларга автомобиль юлларының торышы турында мәгълүмат бирүнең административ регламенты (14 нче кушымта).
2.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы җирлекләрнең җирле үзидарә органнарына әлеге карарны исәпкә алып муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын расларга тәкъдим итәргә.
3.Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

Башлык Л. М. Валеева